**Чистай муниципаль районы**
**Түбән Кондрата авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**2021 елның 26 октябре** **№ 14/6**

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Түбән Кондрата авыл җирлеге
биләмәләреннән файдалану һәм
төзелеш алып бару кагыйдәләренә
үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Түбән Кондрата авыл җирлеге Советының 2014 елның 4 июлендәге 61 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Түбән Кондрата авыл җирлеге биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы мәгълүматны тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, Чистай муниципаль районы Түбән Кондрата авыл җирлеге биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре буенча комиссиянең 2021 елның 4 октябрендәге 3 номерлы бәяләмәсен исәпкә алып, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Түбән Кондрата авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРӘ:**


1. «Шәхси торак йортлар төзү зонасы» Ж-1 территориаль зонасы чиген үзгәртү һәм кадастр номеры 16:42:040101:331 булган, 761 кв.м. мәйданлы, Түбән Кондрата авылы, Комсомольская урамы, з/у 31Г адресы буенча урнашкан җир кишәрлеге территориясен «Күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле зона» ОД1 төзелеш зонасына кертү өлешендә, Чистай муниципаль районы «Түбән Кондрата авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре территориясен шәһәр төзелеше зоналаштыру картасына үзгәрешләр кертергә (1 нче кушымта).
2. Әлеге карарны җирлек халкы күпләп җыела торган урыннарда игълан итәргә һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Түбән Кондрата авыл җирлеге
башлыгы Васильев С.В.

2021 елның 26 октябрендәге 14/6 номерлы карарына 1 нче кушымта

Чистай муниципаль районы «Түбән Кондрата авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре территориясен шәһәр төзелеше зоналаштыру картасы

Гамәлдәге нигезләмә:




Кертелә торган үзгәрешләр:

